БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 апреля 2022 г. № 125

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең генераль планын әзерләү кирәк түгеллеге турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре территорияләрендә әлеге җирлекләр территориясеннән гамәлдәге файдалануны үзгәртү күздә тотылмау һәм социаль-икътисадый үсешнең расланган стратегияләре булмау, шулай ук әлеге җирлекләр территорияләрендә Россия Федерациясе территориаль планлаштыру документлары, Россия Федерациясе субъектының территориаль планлаштыру документлары, Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру документлары белән федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмау сәбәпле һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының түбәндәге авыл җирлекләренең генераль планын 2022 елның 31 декабренә кадәр эшләү кирәк түгеллеген танырга:
- Борбаш авыл җирлеге;
- Борнак авыл җирлеге;
- Югары Субаш авыл җирлеге;
- Куныр авыл җирлеге;
- Нөнәгәр авыл җирлеге;
- Смәил авыл җирлеге.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетына 1 пунктта күрсәтелгән авыл җирлекләренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү буенча чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин